ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 5 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Территория комиссияләре әгъзалары саны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан расланa.»;

2) 18 статьяның 15 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«15. Үзләре кергән комиссиянең вәкаләтләре тәмамлануга бәйле рәвештә вәкаләтләр чоры тәмамланган, әлеге комиссиянең яңа составы әгъзалары итеп билгеләнмәгән һәм пенсия яшенә җиткән яисә тиешле вазыйфа буенча вәкаләтләр башкарган чорда хезмәткә сәләтен югалткан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга, муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып санала торган сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган, бу комиссияләрдә даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзаларына эшкә урнашу яисә пенсия рәсмиләштерү чорына (ләкин вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән алып иң күбе өч ай дәвамында) биләгән вазыйфаларына туры китереп билгеләнгән айлык акчалата түләү (акчалата түләү) бирелә, тиешенчә Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль берәмлекләр

уставларында һәм жирле үзидарә органнарының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән бүтән гарантияләр бирелә, моңа күрсәтелгән затларның вәкаләтләрен федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәүгә, бурычларын башкармауга бәйле туктату очраклары керми.»;

3) 21 статьяның 2 өлешендәге беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Комиссияләрнең сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле карарлары, бастырып чыгаруның әлеге Кодекста башка сроклары һәм тәртибе билгеләнгән карарлардан тыш, кабул ителгән көненнән алып биш көн эчендә тиешенчә региональ (республика) дәүләт яисә муниципаль вакытлы матбугат басмаларында бастырып чыгарыла йә сайлаучылар игътибарына башка юл белән җиткерелә, шулай ук башка массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.»;

4) 22 статьяның 3 өлешендәге беренче җөмләдә «аның ышанычлы заты» сүзләрен «федераль законнарда каралган очракларда аның ышанычлы заты йә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 29 статьяның 1 өлешендә «тиешле комиссияләр тарафыннан» сүзләреннән соң «тавыш бирү көненә кадәр 11 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

6) 34 статьяның 9 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү өчен кирәкле барлык документлар кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле тарафыннан тиешле сайлау комиссиясенә Дәүләт Советы депутатларын яисә жирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү (үткәрү) турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән соң килә торган көннән алып 30 көн эчендә тапшырыла. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат итеп күрсәтү өчен кирәкле барлык документлар кандидат тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән соң килә торган көннән алып 30 көн эчендә тапшырыла.»;

7) 36 статьяда:

а) 1 өлештә «(алга таба – сәяси партия)» сүзләрен «(алга таба шулай ук – сәяси партия)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча күрсәтелгән кандидатлар турындагы беркетмәдә (башка документта) кандидатны күрсәтү турында аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туу датасы һәм урыны, төп эш яки хезмәт урыны, били торган вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт итү урыны булмаган очракта – шөгыльләре төре), яшәү урыны адресы булган карар һәм әлеге карар буенча тавыш бирү йомгаклары булырга тиеш. Сәяси партия (аның региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе), бүтән иҗтимагый берләшмә тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча кандидатлар күрсәтү турындагы беркетмә (башка документ) сәяси партия (аның региональ бүлеге яисә

башка структур бүлекчәсе), башка иҗтимагый берләшмә җитәкчесе (яисә сайлау берләшмәсе уставы белән шуңа вәкаләт бирелгән башка зат) имзасы, шулай ук сайлау берләшмәсенең мөһере белән (сайлау берләшмәсе юридик зат булса) таныклана.»;

8) 37 статьяда:

а) 3 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) кандидатлар исемлеген күрсәтү турында кандидатлар исемлегенә кертелгән кандидатларның гомуми саны, фамилияләре, исемнәре, аталарының исеме булган карар һәм әлеге карар буенча тавыш бирү йомгаклары (кандидатлар исемлеге кушымта итеп бирелә);»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Сәяси партия (аның региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе) тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге сайлау берләшмәсе уставы яисә сайлау берләшмәсенең вәкаләтле органы карары белән шуңа вәкаләт бирелгән зат имзасы, шулай ук сайлау берләшмәсенең мөһере белән (сайлау берләшмәсе юридик зат булса) таныклана.»;

9) 40 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) тиешле кандидатлар исемлегенә кертелгән һәм сәяси партия әгъзалары булып торучы гражданнарның сәяси партиянең, аның региональ бүлегенең яисә башка структур бүлекчәсенең даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан рәсми таныкланган исемлеген.»;

10) 47 статьяда:

а) 6 өлештә:

$1^2$ пунктта «39 статьясындагы 5 өлешендә,» сүзләреннән соң «40 статьясындагы $3^3$ өлешендә,» сүзләрен өстәргә;

$6^1$ пунктта «, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 өлештә:

$2^1$ пунктта «, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

$2^2$ пунктта «, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Бермандатлы яисә бердәм сайлау округында әлеге статьяның 11 өлешендә каралган хәлләргә бәйле рәвештә бер кандидат теркәлгән булса, бер кандидатура буенча тавыш бирү кабат тавыш бирүне үткәргәндә, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда рөхсәт ителә. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның кимендә 50 проценты кандидатны яклап тавыш бирсә, ул сайланган дип санала.»;

11) 57 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ – $1^4$ өлешләр өстәргә:

«$1^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләт вакытлы матбугат басмалары дигәндә сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) дәүләт органнары һәм оешмалары булган, һәм (яисә) сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә кадәрге ел өчен федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан аларга эшләү өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән, һәм (яисә) сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясе һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты (субъектлары) өлеше булган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

$1^2$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары дигәндә сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалар булган, һәм (яисә) сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә кадәрге ел өчен җирле бюджеттан аларга эшләү өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән, һәм (яисә) сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә устав (җыелма) капиталларында муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр) өлеше булган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

$1^3$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары дигәндә әлеге статьяның $1^1$ һәм $1^2$ өлешләренең гамәли көче кагылмый торган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

$1^4$. Мәгълүмат тарату территориясенә бәйле рәвештә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары түбәндәгеләргә бүленә:

1) гомумроссия телерадиотапшырулар оешмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә күрсәтүгә лицензиясе булган телерадиотапшырулар оешмалары, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә шартнамә нигезендә башка телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан таратыла торган массакүләм мәгълүмат чараларын (телеканаллар, радиоканаллар,

телепрограммалар, радиопрограммалар) чыгаруны гамәлгә ашыручы телерадиотапшырулар оешмалары;

2) региональ (республика) телерадиотапшырулар оешмалары, ягъни күрсәтүгә лицензиясе булган һәм Россия Федерациясе субъектларының яртысыннан азрагы территорияләрендә, Татарстан Республикасын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларын (телеканаллар, радиоканаллар, телепрограммалар, радиопрограммалар) таратучы телерадиотапшырулар оешмалары, шулай ук әлеге өлешнең 1 пунктында күрсәтелгән телерадиотапшырулар оешмаларының тиешле бүлекчәләре;

3) гомумроссия вакытлы матбугат басмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә тарату өчен теркәлгән басмалар;

4) региональ (республика) вакытлы матбугат басмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысыннан азрагы территорияләрендә, Татарстан Республикасын да кертеп, тарату өчен теркәлгән басмалар.»;

б) 5 өлештә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 47 статьясындагы 3 пунктының» сүзләрен «әлеге статьяның $1^2$ өлешенең» сүзләренә алмаштырырга;

12) 59 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта, агитация чоры кабат тавыш бирүне үткәрү турында тиешле комиссия карары басылып чыккан көннән яңартыла һәм әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә туктатыла. Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында сайлау алды агитациясе кабат тавыш бирүне үткәрү турында тиешле комиссия карары басылып чыккан көннән соң өченче көнне башлана торган чорда эш көннәрендә яңартыла һәм кабат тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатыла. Вакытлы матбугат басмаларында, челтәр басмаларда сайлау алды агитациясе кабат тавыш бирүне үткәрү турында тиешле комиссия карары басылып чыккан көннән соң өченче көнне башлана торган чорда яңартыла һәм кабат тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатыла.»;

13) 60 статьяда:

а) 13 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 14 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

14) 61 статьяда:

а) 1 өлештә «, ә әлеге Кодексның 60 статьясындагы 13 өлешендә күрсәтелгән очракта, шулай ук түләүле эфир вакыты» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешнең беренче җөмләсендә «Республика» сүзен «Региональ (республика) дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә:

беренче җөмләдә «республика» сүзен «региональ (республика) дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

икенче җөмләдә «өстәмә яисә кабат сайлауларда» сүзләреннән соң «, шулай ук кабат тавыш бирүне үткәргәндә» сүзләрен өстәргә;

г) $4^1$ өлештә «, моңа федераль законда каралган очраклар керми» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 5 өлештә «, федераль законда каралган очраклардан тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 7 өлештә:

беренче җөмләдә «әмма тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча,» сүзләреннән соң «ә кабат тавыш бирү үткәрелгәндә – кабат тавыш бирү билгеләнгән көннән алып бер көн узгач, шунын иртәгесеннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кабат тавыш бирү әлеге Кодексның $104^{15}$ статьясындагы 8 өлеше, $128^1$ статьясындагы 12 өлеше нигезендә бер кандидатура буенча уздырылса, шобага салу үткәрелми.»;

ж) 8 өлештә «республика» сүзен «региональ (республика) дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

з) 9 өлешнең беренче җөмләсендә «Республика» сүзен «Региональ (республика) дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

15) 62 статьяда:

а) 1 өлештә «республика» сүзен «региональ (республика) дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «республика» сүзен «региональ (республика) дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә:

беренче җөмләдә «әмма тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча,» сүзләреннән соң «ә кабат тавыш бирү үткәрелгәндә – кабат тавыш бирү билгеләнгән көннән алып бер көн узгач, шунын иртәгесеннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кабат тавыш бирү әлеге Кодексның $104^{15}$ статьясындагы 8 өлеше, $128^1$ статьясындагы 12 өлеше нигезендә бер кандидатура буенча уздырылса, шобага салу үткәрелми.»;

г) 5 өлешнең беренче җөмләсендә «республика» сүзен «региональ (республика) дәүләт» сүзләренә алмаштырырга;

16) 69 статьяның 2 өлешендә «биш мең» сүзләрен «унбиш мең» сүзләренә алмаштырырга;

17) 76 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда сайлаучы үзе актив сайлау хокукына ия булган бермандатлы сайлау округыннан читтә булу урыны буенча тавыш биргән очракта, мондый сайлаучы республика сайлау округы буенча тавыш бирү өчен генә сайлау бюллетене алырга хокуклы.»;

18) 77 статьяның 1 өлешендә «әлеге сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелгән һәм шикле, гаепле затларны сак астында тоту урыннарында булган» сүзләрен «сайлаучылар исемлегенә кертелгән, ләкин Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә тавыш бирү бинасына керү мөмкинлеге бирелми торган хөкем чарасы сайланган» сүзләренә алмаштырырга;

19) 91[1] статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Округ комиссияләре төзелмәскә мөмкин. Бу очракта округ комиссиясе вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән территория комиссиясе башкарырга мөмкин.»;

20) 101 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тавыш бирү көненнән алып ике ай эчендә Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре турында тулы белешмәләрне, шулай ук барлык сайланган депутатлар турында әлеге Кодексның 75 статьясындагы 6 өлешендә каралган белешмәләрне рәсми бастырып чыгара (игълан итә). Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре турында тулы белешмәләр рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көннән соң өч ай эчендә барлык сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы, сайлау нәтиҗәләре хакындагы беркетмәләрендә булган белешмәләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.»;

21) 104[4] статьяның 5 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кандидатны күрсәтүне хуплау өчен кирәкле затлар саны вакланмалы сан белән билгеләнсә, ул якындагы зуррак тулы сан ягына түгәрәкләндерелә.»;

22) 104[5] статьяда:

а) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Йомгаклау беркетмәсендә, шулай ук тикшерү ведомостенда әлеге Кодексның 104[5] статьясындагы 5 өлеше нигезендә саналмаган имзалар саны, аларны шундый итеп тану нигезләрен бәян итеп, күрсәтелергә тиеш.»;

б) 10 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

23) 104[14] статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тавыш бирү көненнән алып ике ай эчендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турында тулы белешмәләрне, шулай ук сайланган Татарстан Республикасы Президенты турында әлеге Кодексның 75 статьясындагы 6 өлешендә каралган белешмәләрне рәсми бастырып чыгара (игълан итә). Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турында тулы белешмәләр рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көннән алып өч ай эчендә барлык сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Президентын

сайлаулар нәтиҗәләре хакындагы беркетмәсендә булган белешмәләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.»;

24) 104[15] статьяда:

а) 2 өлештәге икенче җөмләдә «, һәр теркәлгән кандидатның үз кандидатурасы буенча кабат тавыш бирү үткәрүгә ризалыгы турында язма гаризасы булса гына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Сайлау алды агитациясе кабат тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатыла.»;

25) 10 нчы кушымтада:

а) «(эш яисә хезмәт урыны, били торган вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт итү урыны булмаган очракта – шөгыльләре төре)» юлында җөмлә башына «төп» сүзен өстәргә;

б) искәрмәдә икенче җөмләне төшереп калдырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13[1] статьяның 2 пунктында «, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 14 статьяның 4 пунктында:

а) «б» пунктчасында «, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «б[1]» пунктчасында «, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 22 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Референдум комиссияләренең референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле карарлары, бастырып чыгаруның әлеге Законда башка сроклары һәм тәртибе билгеләнгән карарлардан тыш, кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә төбәк (республика) дәүләт вакытлы матбугат басмаларында бастырып чыгарыла йә референдумда катнашучылар игътибарына башка юл белән җиткерелә, шулай ук башка массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.»;

4) 26 статьяның 1 пунктында «белешмәләргә таянып,» сүзләреннән соң «тавыш бирү көненә кадәр кимендә 11 көн кала» сүзләрен өстәргә;

5) 33 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ – $1^4$ пунктлар өстәргә:

«$1^1$. Федераль закон нигезендә дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләт вакытлы матбугат басмалары дигәндә референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) дәүләт органнары һәм оешмалары булган, һәм (яисә) референдумны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә кадәрге ел өчен федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан аларга эшләү өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән, һәм (яисә) устав (җыелма) капиталларында референдумны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә Россия Федерациясе һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты (субъектлары) өлеше (кертеме) булган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

$1^2$. Федераль закон нигезендә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, муниципаль вакытлы матбугат басмалары дигәндә референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалар булган, һәм (яисә) референдумны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә кадәрге ел өчен җирле бюджеттан аларга эшләү өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән, һәм (яисә) устав (җыелма) капиталларында референдумны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр) өлеше (кертеме) булган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

$1^3$. Федераль закон нигезендә дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары дигәндә әлеге статьяның $1^1$ һәм $1^2$ пунктларының гамәли көче кагылмый торган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

$1^4$. Мәгълүмат тарату территориясенә бәйле рәвештә Федераль закон нигезендә телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары түбәндәгеләргә бүленә:

а) гомумроссия телерадиотапшырулар оешмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә күрсәтүгә лицензиясе булган телерадиотапшырулар оешмалары, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә шартнамә нигезендә башка телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан таратыла торган массакүләм мәгълүмат чараларын (телеканаллар, радиоканаллар, телепрограммалар, радиопрограммалар) чыгаруны гамәлгә ашыручы телерадиотапшырулар оешмалары;

б) төбәк (республика) телерадиотапшырулар оешмалары, ягъни күрсәтүгә лицензиясе булган һәм Россия Федерациясе субъектларының яртысыннан артыгы

территорияләрендә, Татарстан Республикасын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларын (телеканаллар, радиоканаллар, телепрограммалар, радиопрограммалар) таратучы телерадиотапшырулар оешмалары, шулай ук әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән телерадиотапшырулар оешмаларының тиешле бүлекчәләре;

в) гомумроссия вакытлы матбугат басмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә тарату өчен теркәлгән басмалар;

г) төбәк (республика) вакытлы матбугат басмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысыннан азрагы территорияләрендә, Татарстан Республикасын да кертеп, тарату өчен теркәлгән басмалар.»;

б) 5 пунктта:

«Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Референдум үткәргәндә» сүзләренә алмаштырырга;

«Федераль законның 47 статьясындагы 3 пунктының» сүзләрен «әлеге статьядагы $1^2$ пунктының» сүзләренә алмаштырырга;

6) 37 статьяда:

а) 2 пунктта «Дәүләт телерадиотапшыруларының төбәк оешмалары» сүзләрен «Дәүләт телерадиотапшыруларының төбәк (республика) оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «Дәүләт телерадиотапшыруларның һәр төбәк оешмасы» сүзләрен «Дәүләт телерадиотапшыруларның һәр төбәк (республика) оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктта «, федераль законда каралган очраклардан тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 51 статьяның 1 пунктында «әлеге референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән һәм шикле, гаепле затларны сак астында тоту урыннарында булган» сүзләрен «референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән, ләкин Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә тавыш бирү бинасына керү мөмкинлеге бирелми торган хөкем чарасы сайланган» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 6 пунктындагы беренче абзацта «Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм

референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяда «федераль закон белән» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяның 7 пунктындагы икенче абзацта «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяның 2 пунктында «, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 16 статьяның 2 пунктында:

а) «а» пунктчасында «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

б) «б» пунктчасында «әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) «$б^1$» пунктчасында «, әгәр федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 18 статьяда:

а) 1 пунктта «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

7) 19 статьяда:

а) 3 пунктта «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

в) $4^1$ пунктта «федераль законны» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законны» сүзләренә алмаштырырга;

г) 13 пунктта «Федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

8) 24 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Референдум комиссияләренең референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле карарлары кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә, бастырып чыгаруның әлеге Законда башка сроклары һәм тәртибе билгеләнгән карарлардан тыш, тиешенчә региональ (республика) дәүләт яисә муниципаль вакытлы матбугат басмаларында бастырып чыгарыла йә референдумда катнашучылар игътибарына башка юл белән җиткерелә, шулай ук башка массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.»;

9) 25 статьяның 1 пунктында «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

10) 27 статьяның 1 пунктында «тиешле комиссияләр» сүзләреннән соң «тавыш бирү көненә кадәр кимендә 11 көн кала» сүзләрен өстәргә;

11) 28 статьяның 1 пунктында «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

12) 31 статьяның 4 пунктында «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

13) 33 статьяның 1 пунктында «федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

14) 35 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ – $1^4$ пунктлар өстәргә:

«$1^1$. Федераль закон нигезендә дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләт вакытлы матбугат басмалары дигәндә референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) дәүләт органнары һәм оешмалары булган, һәм (яисә) референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә кадәрге ел өчен федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан аларга эшләү өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән, һәм (яисә) устав (җыелма) капиталларында референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә Россия Федерациясе һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты (субъектлары) өлеше (кертеме) булган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

$1^2$. Федераль закон нигезендә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, муниципаль вакытлы матбугат басмалары дигәндә референдум билгеләү турында

карар рәсми басылып чыккан көнгә гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалар булган, һәм (яисә) референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә кадәрге ел өчен җирле бюджеттан аларга эшләү өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән, һәм (яисә) устав (җыелма) капиталларында референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлекләр) өлеше (кертеме) булган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

1[3]. Федераль закон нигезендә дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары дигәндә әлеге статьяның 1[1] һәм 1[2] пунктларының гамәли көче кагылмый торган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары аңлашыла.

1[4]. Мәгълүмат тарату территориясенә бәйле рәвештә Федераль закон нигезендә телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары түбәндәгеләргә бүленә:

а) гомумроссия телерадиотапшырулар оешмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә күрсәтүгә лицензиясе булган телерадиотапшырулар оешмалары, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә шартнамә нигезендә башка телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан таратыла торган массакүләм мәгълүмат чараларын (телеканаллар, радиоканаллар, телепрограммалар, радиопрограммалар) чыгаруны гамәлгә ашыручы телерадиотапшырулар оешмалары;

б) региональ (республика) телерадиотапшырулар оешмалары, ягъни күрсәтүгә лицензиясе булган һәм Россия Федерациясе субъектларының яртысыннан азрагы территорияләрендә, Татарстан Республикасын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларын (телеканаллар, радиоканаллар, телепрограммалар, радиопрограммалар) таратучы телерадиотапшырулар оешмалары, шулай ук әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән телерадиотапшырулар оешмаларының тиешле бүлекчәләре;

в) гомумроссия вакытлы матбугат басмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысы яисә яртысыннан артыгы территорияләрендә тарату өчен теркәлгән басмалар;

г) региональ (республика) вакытлы матбугат басмалары, ягъни Россия Федерациясе субъектларының яртысыннан азрагы территорияләрендә, Татарстан Республикасын да кертеп, тарату өчен теркәлгән басмалар.»;

б) 4 пунктта:

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Референдум үткәргәндә» сүзләренә алмаштырырга;

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 47 статьясындагы 3 пунктындагы» сүзләрен «әлеге статьяның 1[2] пунктындагы» сүзләренә алмаштырырга;

15) 38 статьяның 1 пунктында «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

16) 39 статьяда:

а) 5 пунктта «, федераль законда каралган очраклардан тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6 пунктта «Әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

17) 46 статьяның 10 пунктында «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

18) 52 статьяның 14 пунктында «Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

19) 53 статьяның 1 пунктында «әлеге референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән һәм шикле, гаепле затларны сак астында тоту урыннарында булган» сүзләрен «референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән, ләкин Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә тавыш бирү бинасына керү мөмкинлеге бирелми торган хөкем чарасы сайланган» сүзләренә алмаштырырга;

20) 56 статьяның 9 пунктында «федераль законның» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның» сүзләренә алмаштырырга;

21) 57 статьяның 2 пунктында «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

22) 60 статьяның 5 пунктында «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

23) 61 статьяның 3 пунктында «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

24) 63 статьяда «федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

«Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 2 өлешендәге 2[1] пунктында «, әгәр федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 22 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Чакыртып алу комиссияләренең чакыртып алуны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле карарлары кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә, бастырып чыгаруның әлеге Законда башка сроклары һәм тәртибе билгеләнгән карарлардан тыш, региональ (республика) дәүләт вакытлы матбугат басмаларында бастырып чыгарыла йә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар игътибарына башка юл белән җиткерелә, шулай ук башка массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.»;

3) 25 статьяның 1 өлешендә «белешмәләргә нигезләнеп,» сүзләреннән соң «тавыш бирү көненә кадәр кимендә 11 көн кала» сүзләрен өстәргә;

4) 34 статьяның 5 өлешендә «, федераль законда каралган очраклардан тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 47 статьяның 1 өлешендә «шушы чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән һәм шикле, гаепле затларны сак астында тоту урыннарында булган» сүзләрен «чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән, ләкин Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль кодексы нигезендә тавыш бирү бинасына керү мөмкинлеге бирелми торган хөкем чарасы сайланган» сүзләренә алмаштырырга;

6) 54 статьяның 3 өлешендә «Федераль законда» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 05 апрель
№ 32-ТРЗ